Распространяется бесплатно.
Май, 2014 №4

# ЖИТЕЛЬ

Сабантуе мөбәрәк булсын!

**Хаджитархан - Хаҗитархан - Астрахань**

*Газета астраханских тюрко-татар*

*Дорогие астраханцы, гости нашего города и области!*



От всей души поздравляю вас с древним татарским праздником плуга - Сабантуй. Сегодня Сабантуй не только праздник плуга, но и праздник мира, единства.

Сабантуй в многонациональной Астрахани давно превратился в общенациональный праздник. Как звучит в известной татарской песни: «уйнап көлеп күңел ачый көн буе, - как работаем, так и отдыхаем на Сабантуе». А наши астраханцы - народ мирный и трудолюбивый. Желаю всем мира и добра в каждый дом. А мы, в свою очередь, дарим вам очередной тюрко-татарский номер спецвыпуска нашей газеты.

**Депутат Астраханской Областной Думы,**
**Председатель Астраханского отделения**
**политической партии «Справедливая Россия»**
**Олег Шеин**

## Редкие музейные экспонаты у себя не можем сохранить, вынуждены передать в Казань

***В 2012-2013 годах Фонд сохранения историко-культурного наследия астраханских татар и тюрков «Хажитархан» передал для хранения и научного исследования татарские художественные книги, напечатанные в начале XX века арабской вязью.***

Среди безвозмездно переданных экспонатов имеется рукопись пока нам неизвестного автора, собранная в одну книгу, в обложке из натуральной кожи. Написана аккуратным подчерком, на хорошей бумаге и стойкими чернилами. Книга толстая, сохранена хорошо. Она найдена в селе Наримановского района, во время разборки старого дома хозяевами, между стенами, среди опилок. При беглом осмотре книги, я увидела дату, написанную рукой автора: 1845 года. Наверное, эта книга и другие многие экспонаты должны были остаться у себя на родине - в Астрахани, только не в частных руках. Но у нас в области нет Государственного музея по истории астраханских татар (такие редкие рукописи должны сохраняться в государственных учреждениях, они требуют определенных условий хранения и обращения). Также у нас нет текстологов-арабистов, изучающих старые рукописи. Книгу мне подарили в 2007 году мои ученики - воспитанники, последователи.

В 2014 года также ученым Казани передан необычный экспонат - черный камень. Камень с величину ладони, на ощупь холодный, натуральный. На какой графике на нем написано нам не известно. Это и ни старославянская, и ни арабская вязь (имеется 12 образцов арабской вязи), и ни иврит, и ни латынь, и ни иероглифы Китая, Японии. Создается впечатление что, на камне написано вертикально, между строк начерчена строго прямая линия. В Казани тоже сразу не взялись сказать, что за письменность и к какому народу принадлежит эта реликвия.

В свое время врач Рауф әфәнде подарил мне женское украшение - калфак, с его слов, калфаку примерно 100-120лет, принадлежал женщинам этой семьи, возможно, привезли из Казани. Основа-темно синий бархат, вышито мелким бисером красивый цветок, требует реставрации специалистов. Я в свою очередь реликвию подарила в Государственный музей Татарстана.

**Наиля Потеева**

## «Сөембикә- гүзәл атым, нугай затым. Кайда минем хан дәүләтем?!»

***«Сюмбике — главная фигура своей эпохи». Михаил Худяков***

***«Сюмбике» - в начале XXI века символ свободы в Астрахани.***



*Скульптура Сюмбике. Работа Бакый Урманче*

8 июля 1999 года во время выездного заседания Всемирного конгресса татар в Астрахани был создан «Ак калфак». Женская организация «Ак калфак» работает не только в Казани, в Татарстане, в РФ, но и в странах СНГ. Первым делом я обратилась образу Казанской царицы-дочери ногайского мурзы Йосыфа - Сюмбике, начала изучать роль Сюмбике в тюрко-татарском мире. С середины 2001 года «Ак калфак» расширили, начали сотрудничать с ногайцами, с начала 2002 года переименовались в Астраханское областное общественное тюрко-татарское объединение «Сюмбике». Идея создания «Сюмбике» получила одобрение видных тюрских и мусульманских деятелей Астрахани и за ее пределами. В честь учредительной конференции - 5 марта 2002 года поставили отрывок из спектакля «Таҗ бөркү-Коронация» - «Сөембикәнең Ак калфагы». По сценарию ногайского мурзы Сюндек засватана за Казанского хана Джангали. Она в кругу своих близких. Ученый ханского дворца предсказывает Сюндек (в дальнейшем, в Казани она становится Сюмбике) тяжелую, но громкую историческую судьбу в тюрском мире. Ногай йорты готовит подарки для Казани. Ногайская молодежь и женщины дарят уникальные ручные изделия. Ногай анасы - Ак тәтә дарит фольклор своего народа-кушавазы, баиты. Ученый ханского дворца-книгу, где накоплена многовековая мудрость ногайского народа. Главный подарок Казанскому хану, от родителей невесты - Священный Коран и мечь для защиты Отечества. И Сюндек готовит подарок для Казани. Подарком оказывается никому до этого неизвестное женское украшение, вышитое золотом и украшенное драгоценными камнями. Сюндек дает ему имя «Ак калфак». Мать Сюндек предсказывает вечную славу Ак калфак: «Сөембикәнең ак калфагы гасырларга тиң булыр!»

Образ Сюмбике впервые был представлен на Астраханской сцене. Постановка вызвала большой интерес в ученых кругах Дагестанских и Карачаево-Черкесских, Ставропольских ногайцев. Действительно, подарок дочери ногайского хана - Сюмбике оказался по душе женщинам Казанского ханства. На примере Ак калфак у женщин других национальностей появились подобные украшения, например, у русских - кокошник и т.д.

Продолжали работу начатую в «Ак калфаке», со своей Программой «В тюрко-татарском мире», куда входит изучение татарского языка, истории Хаджитархана, Казанского и Крымского ханства, Волжской Булгарии, Золотой Орды, и т.д.

8 августа 2002 на литературном вечере, посвященном ханбикә, было объявлено: 2003 год - в Астрахани год Сюмбике.

АОО «Сюмбике» было представлено на Ш Всемирном конгрессе татар в Казани в августе 2002 года. После конгресса состоялся прием в редакции журнала «Сюмбике» главным редактором Ф. Бадретдиновой.

В феврале 2003 года в селе Растапуловка Приволжского района Астраханской области возложен первый камень мечети «Сюмбике».

4 марта 2003 года в рамках «Джанибековских чтений» в Астрахани состоялась первая официальная встреча журнала «Сюмбике» с тюрко-татарской интеллигенцией. Заведующая отделом журнала Филиса ханум Хакимова, фотокорреспондент Газинур Хафизов из Казани на Астраханской земле встретились с Главой мусульманского духовенства области, представителями админстрации города, членами АОО «Сюмбике», татарского областного общества «Хаджи-Тархан», ногайского «Бирлик», делегацией из Карачаево-Черкессии, также из Ногайского района Дагестана, в том числе членами редколлегии ногайской газеты «Голос степи». Официальная часть встречи началась с чтения сур из Корана муфтия области Назымбека Ильязова. В честь гостей АОО «Сюмбике», татарским обществом «Хаджи - Тархан» была организована встреча и концерт с названием «Чорлар аша дәшә Сөембикә». Создание АОО «Сюмбике» в Астрахани является началом демократических преобразований тюрко-татарских обществ, которые были необходимы в начале XXI века.

Пользуясь случаем, за оказанную консультативную помощь в первые годы объединения «Сюмбике», выражаю благодарность председателю ногайского общества «Бирлик», историку Джуманову Равилю Утемухамедовичу.

**Председатель Астраханского областного общественного тюрко-татарского объединения "Сюмбике"**
**Потеева Наиля**

# «Таҗ бөркү– Коронация»

## спектакленнән 1нче бүлек: «Сөембикәнең Ак калфагы»

Катнашалар: Йосыф морза, Сөендек-Сөембикә, Сөедекнең әнисе-исеме тарихта билгесез, Нугай анасы- Ак тәтә, хан сарае укымышы, Сөендекнең тәтәләре, ир туганы, кече энесе, Сөмбелә-Сөендекнең якын дусты, нугай яшьләре: кызлар һәм егетләр.

Сөендек үзенең якыннары: ата-анасы, тәтәләре, туганнары, хан сарае укымышы, якын дус кызы- Сөмбелә, нугай яшьләре арасында. Алар бар да милли киемнәрдән. Яшьләрнең кулларында кыллы уен кораллары, егетләрдә хәрби кораллар: айбалта, кылыч, ук-җәя, һ.б.

Сәхнә урта гасырларның нугай ханы сарае стилендә бизәлгән:диварларда келәмнәр, ятакларда затлы хайван тиреләре, күн тышлы мендәрләр. Сәхнәдәге халык ярымтүгәрәк итеп утырганнар. Уртада Йосыф морза, уң ягында ханбикәсе, Сөендек, аларның ян-якларында якыннары, укымышлар, яшьләр. Сәхнәдә әкрен генә дала җилләре исүен, чабып барган ат кояклары тавышын хәтерләткәндәй нугай көе яңгырый.



*Портрет Сююмбике*

***Йосыф мырза вәкарь белән:*** Нугай иле зур эшләр алдыннан тора.

***Сөендекнең әнисе горурлык белән:*** Сөендегебез Казан ханы Җангалигә ярәшелде.

***Хан сарае укымышы:*** Хан сараенда зур эшләр алдыннан фал ачу лазимдыр.

*(Сөендекнең кече энесенең күзен яшел ефәк белән бәйлиләр һәм ул «фал китабын ачып» Хан сарае укымышына бирә).*

***Хан сарае укымышы*** «хан кызының язмышын бага» да, аннан хан даирәләренә җиткерә: Тәңремез зур сынаулар, авырлыклар аша Сөендеккә төрки доньясында шөһрәтле вә данлыклы язмыш юллый.

***Йосыф мырза:*** Кызым, Казанда синең артта төрки доньясы торачак: Нугай йорты, Хаҗи-Тархан-Әстерхан ханлыгы, Кырым ханлыгы. Аннан, Казанга синең белән атлы чирү (войска), бәкләр, сәүдәгәрләр, кәсепчеләр вә 3 мең нугай күчеп китәчәк.

***Сөендекнең әнисе:*** Кызымыз җашь (яшь) бит әле. Казанда гомер-бакый ханнар алышынып, Казан гел кайнап торган. Казан каласы тыныч урын түгел.

***Йосыф мырза:*** Авызберлек булмау аркасында Алтын-Урданы саклый алмадык. Аның тупрагында җашь урыс дәүләте аякланып килә. Булмаса, безгә Идегәйнең дәвамы итеп Җаектан алып Донга кадәр көчле, бер йодрыкка тупланган төрки-татар дәүләтен төзергә кирәк. Башка чара йук.

***Сөендекнең әнисе:*** Кызымызның башын җылыннар арасына килеп керүдән Ходай үзе сакласын инде.

***Йосыф мырза:*** Казан ханнары Нугай иленнән гомер бакый кыз алганнар. Фатыйма, Нурсолтан – нугай кызлары. Сөендек белән Казанга күчеп киткән минем киңәшчеләрем, руханилар(духовенства), чичәннәр (поэты), кызымның дус кызлары хан сараенда торачак. Сәяси никахның шарты шундый.

***Сөендекнең әнисе:*** Аллага мәдәт. Ярар, хәзергә әйдәгез, Сөендекнең бирнәсен барлыйк.

***Йосыф мырза:*** кызым, син безнең өчен Сөендек. Төрки доньясы өчен бүгенге көннән башлап син - Сөембикә-ханбикә, ил, дәүләт язмышы белән йәши башлаячаксың.

***Нугай кызлары:*** Сөендек, без үзебез белән Казанга кыллы уен коралларын алабыз, далага, сахраларга чыгармыз, Сарайдагы кебек домра чиертермез, кабал сугармыз.

***Егетләр:*** без иң яхшы чапкыннарыбызны, ук белән җәяләремезны аламыз. Анда да алтын кабак, дала уеннарын дәвам итәрмез, башкаларны да өйрәтермез.

***Сөендекнең тәтәләре:*** Сөендек, без сиңа нугай халкының иң матур келәмнәрен бүләк итәмез, Хан сарайларың, мәчетләрең чук кебек балкып торсын *(бүләккә келәмнәр һәм башка кул эшләрен бирәләр)*.

***Нугай анасы - Ак тәтә:*** Сөендек, балам, күз нурым, мин сиңа халкымның гомерлек кушавазларын, бәетләрен бүләк итәм. Алар сине авыр вакытларыңда юатыр, сагышларыңны басар *(зур, калын китап бирә)*.

***Хан сарае укымышы:*** Сөембикә, бу китапта нугаемның гомерлек акыл байлыгы, ханнарымызның данлы үткәне, шанлы дәүләте-Алтын-Урда тарихы. Дәүләтең Алтын-Урда кебек данлы, халкың дала халкы кебек бәйсез, көчле булсын *(шулай ук зур, калын китап бирә)*.

***Сөендекнең әнисе:*** Кызым, Казан ханына атаң белән бездән бүләкнең олысы: Изге Көрьән. Халкың иманлы булсын, мәчетләр, мәдрәсәләр салдырырсың *(Көрьән китабын җирле гадәт буенча Йосыф морза баштан күкрәгенә алып кыса да, аннан Көрьәнне үбеп маңгаена тидереп ала да, кызына бирә. Кызы да шул ук гамәлләрне башкара да атасы-анасы алдына килеп баш ия)*.

***Йосыф мырза:*** Көрьәнгә кушып көмеш айбалта бүләк ителәә. Бабаларымыз бу айбалта белән данлы көрәшләрдә зур җиңүләр яулаганнар. Кызым, нәсел айбалтасына ия булырдык азамат ханзәдәләр, җиһангирлар үстер *(кызына айбалта бирә, Сөендек аны үз чиратында арткы пландарак торган үзенең җиһангирына бирә)*.

***Сөендек:*** Атам, бу айбалтаның сере нәрсәдә?

***Йосыф мырза:*** Башка кавемнан булган кияү ханга туй бүләге итеп айбалта тапшыру нугайда булган хәл түгел. Моның бик җитди сәбәпләре бар. Әйе, бүген татар, нугай ханлыкларының хәле шундыйлардан.

***Сөендекнең ир туганы:*** Атам, ни өчен Казан халкының үз ханы юк, Кырымнан, Нугай иленнән хан



*Территория Казанского Кремля, башня Сююмбике*

соратып алалар. Нугайда бит хан булу өчен Алтын Урдадан килгән гомерлек көрәш бара.

***Йосыф мырза:*** Казан ханлыгына нигез салган Ибраһим ханның ир баласы булмый, шуннан нәсел киселә.

***Сөендекнең ир туганы:*** Ни өчен нугай илендә дә ханлык тирәсендә авызберлек юк, Исмәгыйль кахабыз читтә йөри, безнең белән түгел, Мәскәү белән дус.

***Йосыф мырза:*** Нугай иленең тормышын төптән үзгәртергә кирәк. Элеккечә күчмә тормыш белән яшәп булмый. Беренче гамәлем: акку (аккош) кебек матур кызымны Казанга бүләк итәм.

***Сөендек:*** Атам-анам, тәтәләрем, кардәшләрем, дусларым, бүләкләрегез өчен рәхмәт. Алар сагынганда минем сагышымны басарлар, арыганда көчкөдрәт бирерләр. Максатыма ирешергә булышырлар.

***Сөмбелә:*** Сөендек тә Казанга бүләк әзерли.

***Йосыф мырза:*** Кызым, күрсәт бүләгеңне.

*(Сөендек атасы алдына бөркәнчеккә беркетелгән таҗ чыгарып сала. Таҗ Ак калфак рәвешендә, бик матур итеп эшләнгән, алтын җепләр белән чигелгән, асыл ташлар белән бизәлгән. Йосыф морза ак калфакны кызының башына кидерә, әнисе бөркәнчекне рәтли, аңа Сөмбелә белән башка кызлар да кушыла).*

***Нугай яшьләре Ак калфак тирәсенә җыелып:*** нинди гаҗәп матурлык.

***Кызлар:*** Алтын җепләр белән чигелгән.

***Сөмбелә:*** асыл ташлар белән бизәлгән.

***Йосыф мырза:*** Сөендек бу ни зат?

***Сөендек:*** Ак калфак. Мин аны Казан кызларына бүләк итеп алып барам.

***Сөендекнең әнисе:*** Сөембикәнең Ак калфагы гасырларга тиң булыр.

***Йосыф мырза:*** Кызым, булдыргансың. Бүләкнең дә дәрәҗәлесен ясагансың. Әмма Казан ханлыгына иң зур бүләк син үзең!

***Нугай бәге:*** Йосыф мырза! Чапкын хәбәр китерде: Казан кодаларымыз безгә җитеп киләләр.

***Йосыф мырза:*** Казансу кодаларымыз белән төрки доньясын җыеп аласы бар. Кузгалабыз, вакыт җитте.

*(Йосыф морза артыннан хатыны, олы яшьтәгеләр барысы да чыгып китә. Сәхнәдә яшьләр генә кала. Сөембикә уртада, яшьләр уен башлый).*

**Язды һәм сәхнәгә куйды Наилә Яуширмәле**

# «Сөембикә беләзеге– Серебряный браслет «Сюмбике» в Астрахани

***С 1999 года Всемирный татарский женский журнал «Сююмбике» учредил специальный приз – «Сөембикә беләзеге».***

Браслет сделан из серебра, с барельефом Сююмбике, готовится по специальному заказу, по эскизу лауреата, выдающегося татарского скульптора и художника Бакый Урманче – Наили Кумысниковой.

За этот период присвоено всего 16 браслетов: Семь лауреатов проживает в городе Казани, среди них такие «жемчужины» татарского мира как: ***Туфитуллова Роза Рахматулловна*** – бывший редактор журнала «Сююмбике», учредитель и председатель женской ассоциации «Ак калфак», депутат Госсовета Респубилики Татарстан, ныне член общественной палаты Госдумы России; Сафиуллина Флера – ученая, профессор, завкафедой Казанского Государственного университета. Девять лауреатов проживают в самых разных точках земного шара: София Губайдуллина – в Германии, Шамсия Апакай – в США, внучка Садри Максуди - Голтэн Ураллы в Турции, редактор газеты «Нур» Альфинур Гафурова в Санкт-Петербург, великая татарская певица Фарида Кудашева-в Уфе, редактор журнала «Ак калфак» в Тюмени- Бибинур Сабирова (Тюмен). Шестнадцатый браслет Казанской царицы Сююмбике ханбике достался Астрахани.

**Из фонда «Сююмбике» (30 декабря, 2005 года)**



## Сөембикә— Ханбикә

Йосыф мырза кызы Сөембикә
Муса ханның сөекле оныгы,
Мин дә Исхак мырзаның иң олы
Беренче кадерле оныгы.
Якын,- дип белгәннән бирле
Эзләдем гомерем буе,
Әбием сүзләреннән,
Нәселем эзләреннән.

Китаплар битләреннән,
Журнал һәм гәзитләрдән,
Легенда, риваятьләрдән,
Җырлар һәм бәетләрдән.
Гасырлар арасыннан
Син карыйсың елмаеп,
Күзләреңдә тулы
Кардәшлек нуры,

Өзелмәгән икән нәсел
җепләре,
Сүрелмәгән әле кардәшлек
хисләре,
Матурлык, гүзәллек,
Акыллы-тапкырлык,
Тынычлык, түземлек,
Ирекле - иркенлек—

Боларның барсы — бабайлар
каны,
Тәрбия биргән
Нугайның даласы.

***Зөлхәбирә Ишбердиева.***
***Сентябрь, 2000ел.***

## На юбилее журнала «Сюююмбике»

***18 декабря 2005 года в Татарском академическом театре оперы и балета им. Мусы Джалиля, в городе Казани, прошел 80-летний юбилей журнала «Сююмбике». На котором астраханская делегация имела особую миссию.***

Совет АООО «Сююмбике» решил создать объединенную делегацию из своих членов в лице астраханских татар, астраханских ногайцев и ногайцев из Карачаево-Черкессии. Наша делегация была самая многочисленная, солидная, яркая, представительная. В основном вся делегация была впервые в Казани.

Официальная часть праздника началась с экскурсии по Казани - с посещения самой старой мечети имени Шигабутдина Марджани, заповедника «Туган авылым – родное село мое», и, конечно же, Казанского-Кремля. Перед нами были открыты объекты мирового значения: мечеть Кул Шариф, к сожалению, мало кто знает, что он родом из наших Астраханских степей, и знаменитая башня Казанской царицы Сююмбике. Было очень трогательно видеть слезы радости на лице нашей делегации у башни Сююмбике. Вечером, в самом красивом театре Казани состоялся юбилейный вечер журнала, где нас наградили Серебряным браслетом Сююмбике. Наша делегация с первых минут вызвала большой интерес у публики и СМИ. Особый интерес вызвал национальные костюмы у наших ногайских девушек. После юбилейных мероприятий, на следующий день, нашу делегацию приняли в редакции журнала.

***Из фонда «Сююмбике», декабрь, 2005.***



**На Ш Всемирном конгрессе татар:**
**слева направо: Альфинур Гафурова (СПб), Роза Туфитуллова (Казань), Наиля Потеева (Астрахань), Гольнафис Халимдарова (Казань).**

## «Сөембикә» журналы бездә кунакта

***Без - «Сөембикә» берләшмәсе, «Эдигей» нугай яшьләре оешмасы (рәисе Илдар Идрисов) 2007 елның 26-28 апрелендә «Сөембикә» журналын кабул иттек.***

Баш мөхәррир Фирая ханым Бәдретдинова, шагыйрә Илсөяр Иксанова, журналист Гөлнур Сафиуллина, фотограф Газинур Хафизов бездә кунакта булып киттеләр. Матур итеп узган бу очрашуга Сөембикә журналының 10нчы санының (2007ел) яртысы багышланганга, артык тукталып тормыйм. Кунакларның Әстерханда 1нче көне г.Тукайның туган көненә туры килүе дә бик күркәм булды. «Сөембикәләрне» бу көнне г.Тукай 1911 елда булып киткән татар бистәсе Тияккә, элеккеге Кызыл Шәрек клубы, Татар базар, каланың иске татар бистәсе - мәчетләр тирәсенә, Кремльгә, Әстерхандагы Иран сәнгате үзәгенә б.һ. җирләргә алып бардык. Кичен халык җыеп, «Чорлар аша дәшә Сөембикә» исемле рәсми очрашу уздырдык һәм концерт куйдык.

Әстерхан милли татар хәрәкәтендә озак еллар хезмәт куйган 11 кешегә журналның мактау грамоталарын, бүләкләр тапшырдык. 2нче көнне Киләче авылында булдык, берочтан Зөлхәбирә апа Ижбердиевага кердек бу вакытта ул аягын сындырып, өйдә генә йөри ала иде. Тәтәбез шактый гомер авырады, аны шул көннәрдә Киләче авыл советы авырсынмыйча карап, тамагын тук, өстен чиста тотты.

Мөмкинлектән файдаланып, бу изге гамәлләре өчен авыл хакимияте башлыгы Гали әфәнде Абдрахмановка, авыл советы сәркәтибе Хәерниса Бикбулатовага зур рәхмәтебезне язып язам. Төштән соң нугайларга – Растапуловкага чакырулы идек. Мәктәп директоры, Россиянең Атказанган укытучысы Вәли әфәнде Кутламбетов мәктәптә бик үзенчәлекле, гомергә күңелдә калырлык, матур очрашу узды. Очрашуга килгән авыл халкы «Сөембикә беләзеген»: кызыбыз (Сөембикә) кайтты дип, аягүрә басып сәламләде. Урта яшьләрдәгеләр, олылар беләзекне алып, 2 куллап күкрәкләренә кысалар да, аннан үбеп куеп, маңгайларына тидереп торалар. Дагестан, Карачаево-Черкессия, Ставрополь нугайлары белән аралашканда да аларның Сөембикә өчен күңелләрендәге әрнү, сыкрауны үз күзләрем белән күрдем. Күргәннәрне сүзләр белән генә биреп бетереп булмый. 3нче көнне кунаклар, нугай, татар яшьләре белән Алтын Урдада - Сарай әль Сәхрүсәдә (Хәрәбе районы Селитренное авылы янында) булдык. Археолог Евгений Пигарев Алтын Урда буенча безне көн буе озатып, аңлатып-сөйләп йөрде. Хәрәбәледән кунакларыбызны поездга утыртып Казанга озатып калдык.

## Кайтчы Казан иленә, кайтчы Хаҗитархан җиренә

Казан ханлыгына килен булып төшкән Сөембикә Җангали белән нибары ике ел яшәп, тол кала. 1535 елда Казанга килеп яңадан ханлык итә башлаган кырымлы Сафагәрәйгә кияүгә чыга. Аларның уллары Үтәмешгәрәй туа.1549 елны Сафагәрәйнең (42 яшендә) үлеп китүе, казанлыларның да, Сөембикәнең дә улы белән язмышында зур, кискен үзгәрешләр кертә. Сөембикә регентша итеп билгеләнелә һәм Казан белән аның иң авыр вакытларында: 1549-1551 елларда идарә итә. 1551 елның августында (Казанга август аенда килә, август аенда китә дә) Иван Грозный тарафдарлары, Казан хөкүмәтенең килешүе нигезендә ханбикәне улы белән Мәскәүгә алып китәләр. Идарә иткән елларда ул гади халыкка ташламалар ясый, кайбер реформалар үткәрә. Халык аны якын итә, сөеп карый. Халык күңеленә якын булганга, алар үзләренең ханбикәләрен тиз генә оныта алмыйлар. Сөембикә11 августта Казаннан чыгып китеп, 5 сентябрьдә Мәскәүгә килеп җитә. Моннан соң ул ватан һәм бала хәсрәте чигеп, җәһәннәм уты йотып яши башлый. Аны күп газапларга дучар итәләр. Иван Грозный теләге буенча урысларның дусты һәм Казанны басып алуда зур ярдәм күрсәткән Касыйм ханы Шаһгалигә кияүгә бирелә. Әмма Сөембикә моңа һичкайчан күнә алмый. Хәтта, аны, Шаһгалинең хатыны булып тормады, диючеләр була. Касыймлылар аны Бүләкбикә (Касыйм ханлыгына бүләк итеп бирелгәнгә) дип йөрткәннәр. Сөембикәнең әсир ителүе чынлыкта аның гына түгел, ә тулы бер милләткә коллык чылбыры тагу була. Гаиләсен,баласын, ханлыгын югалткан,Казанның җиңелүчәгән сизгән Сөембикә тирән хәсрәткә бата.

Үзенең Касыймдагы әрхурлы тормышын күтәрә алмаган бәхетсез, кайда һәм кайчан үлүе төгәл билгеле түгел.1554 елның гыйнварында Иван Грозный белән Нугай морзалары (Йосыф, Гали, Юныс) арасында Сөембикә турында соңгы ярлыклар язылганы тарихта билгеле. Берәүләр Сөембикәнең 1554 елда Касыйм шәһәрендә вафат булуын фараз кыла. Кабере дә билгеле түгел. Кайбер тарихчылар Сөембикәне Касыймда Шаһгали хан төрбәсендә бер читтәге исемсез кабердә ятуы мөмкин дип күрсәтәләр. Аның бөтенләй башка якта ятуы да бик мөмкин.

## Әстерханда - Киләчедә Сөембикә нәселе саклана

Әстерханның Иделбуе районы, элек Урусовлар - нугай морзасы - Исмәгыйль морза җирләре булган. Исмәгыйль - Сөембикәнең атасы - Йосыф морза белән бертуганнар.

Иделбуе районының Баллы (Болда) елгасы буенда урнашкан Киләче авылында гомерлек укытучы, җирле шагыйрә, җәмәгать эшлеклесе Зөлхәбирә апа Ишбердиева-Урусова яшәде (1929ел5 июль-2011 ел 15ноябрь). Ул – Сөембикә ханбикәнең ерак туганы, канкардәше, нәсел дәвамчысы. Без аның белән икәүләп «Киләчем минем» һәм «Нәселем эзләреннән» исемле китапларын чыгардык. 1999 елның 5-7 июлендә Әстерханда Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының күчмә утыры узды. Әстерханда конгресс үткән көннәрдә - 5июльдә морзалар нәселен дәвам итүче Зөлхәбирә ханыма 70 яшь тулды. Программада каралмаса да, ылыстан (ерактан) килгән кадерле кунакларны, бигрәк тә Роза ханымны морзалар авылына, Зөлхәбирә апаның гомер бәйрәменә алып барасы килде. Зөлхәбирә апаның нәкъ бәйрәм табынына килеп кердек. Әстерханның нугайлары, Казан ягын хан заманнарыннан калган гадәт белән һәрчак олы хөрмәт, тирән ихтирам белән «кадерле кодаларымыз» дип искә төшерәләр һәм аяк өсте басып каршы алалар. Бу юлы да ылыстан - сөекле кызлары ханбикә булып торган җирдән килгән кадерле кунакны нур өстенә- нур итеп, шул гадәт буенча каршы алдылар. Роза ханым халык алдына, шул мәҗлескә урта гасырларны бүгенге белән тоташтырып, Сөембикә-ханбикәдәй килеп кергәндәй булды. Мәҗлес халкы бик үк ышанмыйча, чынмы, Казаннанмы, «Азат хатын» журналының мөхәррире Роза Туфитуллова үземе, дип, исенә килә алмый торды. «Азат хатын» - «Сөембикә» журналыны баш редакторы, хатын - кызларның «Ак калфак» оешмасы рәисе Роза Рахматулловнаның Зөлхәбирә апаны 70 еллык бәйрәме белән котлап китүен Киләче халкы шатланып: Казанда да безне беләләр, онытмаганнар, исәпләшәләр икән дип, бүген дә искә алалар. Шунысын да әйтеп узыйк: нугайлар ачык, кинәясез, эчендәгесе-тышында, кода-кодагый төшенчәсенә изге итеп караган бер халык. Үзенә атап әйтелгән һәр сүзне, һәр гамәлне җиз иләк аша уздыручы Зөлхәбирә апага исә бу вакыйга гомеренең ахырына кадәр тән һәм җан дәвасы булды. Зөлхәбирә апа: Роза Рахматулловнаның Киләчегә килүе – авыл тарихына кереп калды. Минем 70 яшемә иң зур бүләк, гомер юлыма, иҗатыма бәя бирү, җирдә яшәвемнең мәгънәсе, дип бәяләде. Өчебезнең бергә очрашуыбыз бер мизгел генә булса да, киләчәккә бәрәкәтле, тирән тамырлы орлыклар салынган, Сөембикә-ханбикәнең тормыш – гаилә - сәясәттәге ролен өйрәнү өчен шактый тирән буразна ерылып кителгән булып чыкты. Бу тарихи очрашу без-3 шәхесне якынайтты, Сөембикә сукмагына алып килде, иҗат илһамы өстәде.

Зөлхәбирә апа мине баласы кебек күрде. Без якыннар, дус булып яшәдек. Мин аңа еш кына тормыштан шактый четерекле сораулар бирә идем. Тәтәбез җавапларны уйланырлык итеп бирә, мин аңа, боларны каян беләсең, дия идем. Ул вәкарь белән: мин мырза кызы, Исхак мырзаның сөекле оныгы, дия иде. Дөрестән дә Зөлхәбирә ханымның эчке һәм тышкы чагылышындагы кан белән кергән мырзалыкны атеистлар системасы да, тормышның кырыс шартлары да юып төшерә алмады.

## Сафагәрәй белән Сөембикәнең уллары - Үтәмешгәрәй

Үтәмешгәрәйне Мәскәүдә әнисеннән аерып алып, 1553елның 8нче гыйнварында көчләп чукындырып, Александр исеме белән Иван Грозный сараенда тәрбия кылалар. Аның рус әдәбиятын яхшы белүе, укымышлы, акыллы булуы тарихка кереп калган Ливон сугышында татар-төрки сугышчылары белән җитәкчелек иткәне билгеле. Ничек, нинди шартларда вафаты рус тарихында язылмый. Ул Иван Грозныйның «үз кешеләре»нән саналган. Шулай булгач, татар каны- Үтәмешгәрәйнең Русия тәхетенә дә дәгъва кылуы бик мөмкин… Үтәмешгәрәй-Александр 1566 елның 11 июнендә үлеп китеп, Мәскәү Кремленең Архангель некрополь - соборында күмелгәнлеген белә идем.

Санкт-Петербург ГИДУВында укып кайтканда Мәскәүдә туктап, Үтәмешгәрәй хан-баланың каберен эзләп бардым. Некропольгә кергәч үк күз салган, ишеккә якынрак бастырылган колонна янына килдем. «Царь Казанский… во крещении Александр» дигән сүзләрне аңлый алдым. «Некрополи Московского Кремля» исемле китапта Үтәмешгәрәйнең шушы кабердә ятуы турында 4юллык мәгълүмат таптым. Архангельск некрополендә барысы 48 кеше күмелеп, 48нче кабер Үтәмешгәрәй ханныкы дип теркәлгән. Некропольдә Иван Горозный уллары белән, рус патшалары, бөек кнәзләр күмелгән.

### Сөен, Сөем!

Атлар чаба нугай даласында.
Кара төнне яра учаклар.
Яшь сылуның күңел
түрендә дә
Кабынырга торган учак бар.
Тик җил генә иссен,
дөртләп китәр,
Бер елмаю җитәр, бер караш.
Төнне яра очкын.
Күңелендә
Шатлык белән курку аралаш.
Сөен, Сөем,
Сөем, сөенеп кал,
Сөел, сөел назлы
җилләрдән.
Сәясәткә әле бәйләнмәгән,
Казансудан яучы килмәгән.
Җилкендерә җанны, ашкындыра-
Шул мәхәббәт дигән хис
микән?
Алда нинди язмыш көтеп тора-
Алсу таңмы, Моңсу кич
микән?
Йосыфбәкнең гүзәл, назлы
кызы
Сокландырып бөтен даланы
Атта чаба Гөлләр әллә сөеп,
Әллә инде көнләп каламы?
Сөен, Сөем, Сөем, сөенеп
кал, Сөел, сөел назлы
җилләрдән.
Сәясәткә әле бәйләнмәгән,
Казансудан яучы килмәгән.

**Илсөяр Иксанова, Казан**

## Җангали хан белән Сөембикәнең кызы булганмы, кем ул Маһисолтан?

Сөембикәнең Җангали ханнан баласы булганмы? Үтәмешнең тарихка кереп калуы аңлашыла. Ул ике яшендә хан итеп билгеләнелгән бала,- Сафагәрәй ханның улы. Сөембикәнең кызы булган очракта да кыз баланың тарих күләгәсендә калуы бик мөмкин.

Борис Ишбулдин әл-Бәкри үзенең «Татарлар тарихы» дигән китабында: «Әстерхан тәхетенә



1532 елда Мортаза хан улы Аккүбек утыра, ул бары тик бер ел гына Әстерхан хакиме булып кала. Русия тарихчылары Аккүбек угланны Кайбуллла- Абдулла исеме белән беләләр. Ошбу углан 1552 елда Мәскәүгә килә һәм Җангали кызына өйләнә. Бу углан-хан 1555 елда шведларга каршы сугышта урыслар ягында сугыша һәм татар гаскәрләре башында тора. Иван Грозный яңа бүләк итеп, барлык керемнәре белән Юрьев каласын бирә»-, дип яза. Бу кыз баланы тарихчылар, шул исәптән һади Атласов үзенең «Сөембикә» исемле әсәрендә Җангали хан кызы (1534-1535 елларда туган булса кирәк), дип язалар. Җангалины Сөембикәгә яшьләй, 17 яшьләр тирәсендә өйләндерәләр, Сөембикә- Җангалиның ул бердән-бер хатыны. Бу кыз бала Аккүбеккә кияүгә чыканда 17 яшьләр тирәсендә була. Татар газет-журналларында ул кыз баланың исеме Маһисолтан булырга ошаган, дигән фикер укыганым бар. Җангалиның бертуганы- Касыйм ханы Шаһгалиның үз баласы булмый.Әмма ул үзенә туган тиешле 2 кыз баланы: Хансолтан һәм Маһисолтанны тәрбиягә ала. Күрәсең, беркеме дә калмаган, үзе өчен утлы казанга әйләнгән Казан тәхетендә калуга караганда, Сөембикә Мәскәү хозурына «почетлы плен»га китүне артык күргәндер. Күңелендә кызы белән якынлашу, берләшү омтылышы да аны Мәскәүгә ымсындыргандыр, бәлки.

И.В.Зайцевның «Астраханское ханство» (Москва - 2004 г.изд.) китабында да Җангали кызының Аккүбеккә кияүгә чыкканы турында берничә урында языла.

Сөембикәнең бүгенге көндә билгеле булган портретында (17 йөздә билгесез рәссам ясаган) аның янәшәсендә бер бала басып тора. Байтак вакытлар бу баланы Үтәмешгәрәй дип яздылар. Тик соңгы вакытта бу мәсәлә кабат күтәрелде. Этнограф М. Завьялова тәсфилләп анализ ясап, аның кыз бала булуын нигезле итеп исбатлады. Югарыда атап үтелгән рәсемнең мин, XX гасыр дәвамында чыккан китап-журналларда 2 төрен күргәнем бар иде. Алар арасында аерма шактый зур. Күрәсең, рәсем нык бозы-

## Рәсемдә Сөембикә кем белән?

лып, бигрәк тә кешеләрнең йөзләре бөтенләй дә юкка чыккан. Бу ике картинаны реставрацияләгәндә рәссамнар үз фантазияләреннән чыгып эшләгәннәре күренеп тора. Әстерхан өлкәсендә (Иделбуе районының бер авылында) без бу картинаның 3нче вариантына тап булдык. Югарыда әйтеп узылган 2 картина белән чагыштырганда, монысы картинаның төп нөхсәсе (подлинник) йәисә, милли (татар-төрки) рәсамы реставрацияләгәнгә ошый. Кешеләрнең (Сөембикә, аның баласы, арткы планда: хатмәсе-бала караучысы һәм ир кеше-Кошчак ?) йөзләре ачык, матур, нурлы. Сөембикәнең карашы туры, йомшак; йөзе ягымлы, рәсемнән, бу бик матур, гел үзенә тартып торган ханбикә булган дигән фикер туа. Янындагы бала әнисеннән дә матур, аны һич тә ир бала дип булмый. Үтәмешгәрәй дип уйларга теләсәк тә, ир баланы кызлар образына шулкадәр кертмәс иделәр. Рәсем Казанда, «Казан тарихы» китабының башында, 1909 елда «Баянуль-Хакъ басмаханәсендә басылган. Без аны Казанга тәкъдим иттек, рәсем быел «Түгәрәк уен» журналында (редактор Илсөяр Иксанова) да басылып та чыкты.

***Материал 2014елның май аенда язылды.***

## Сөембикә

Сөембикә, Сөембикә
Туып үстең Җаекта.
Шикәр күлдән сулар эчтең,
Аккошлар белән йөздең.
Морза кызы, иркә үстең,
Нугай ил кочагында.
Ат уйнатып, уклар атып,
Батырларга тиң булдың.
Ундүрт яшькә син
җиткәндә,
Киселде балачагың.
Казан килне-Ханбикәсе,
Даның чыкты доньяга.
Килде заман, шәһри Казан,
Камалды һәм җимрелде.
Явызларга әсир булдың,
Халкыңа корбан булдың.
Сөембикә, синең алда
Гаеплебез мәңгегә.
Кайда икән рухың синең?-
Кайтчы Казан иленә,
Кайтчы Хаҗитархан
җиренә.

***Равил Джуманов***

## Чорлар аша дәшә Сөембикә

*2009 елның 18-19 апрелендә Әстерханда Татарстанның халык артисты Зөһрә Сәхәбиева-Бигичева «Сөембикә» мәчетенә хәйрия концерты бирде.*

18 апрельдә ТЮЗда Зөһрә Сәхәбиеваның Әстерхан татар, нугай яшьләре катнашы белән белән Растапуловка авылында салына башланган «Сөембикә» мәчетенә хәйрия концерты узды. Сөембикәне Казаннан алып киткәннән бирле - 460 ел эчендә, атап, аның исеменә багышланган беренче концерт булгандыр бу. Казан-Әстерхан, татар-нугайның бергә кушылып Сөембикәне зур, матур сәхнәдә искә алулары, дөрестән дә беренче тапкыр булды. Концерт-кичә Зөһрә Сәхәбиеваның Әстерханга «Сөембикә чәк-чәген» тапшыруы һәм чәк-чәкнең залдагы тамашачыларга кулдан-кулга китүе белән башланды.

Икенче көнне- 19 апрельдә, Кремль, Аккош күле тирәсен сәяхәт кылып, Әстерхан татарлары тупланып яшәгән төбәк-Хаҗитарханның үзәге булган Татар базар тирәсендә, Тияктә булып, Татар Башмаковка (Кзан) авылына, кичкә таба концертка юл тоттык. Авыл Казан кунакларын «Хуш килэсез, кодаларымыз» дип каршы алды. Монда Казан халкына хан заманнарыннан калган гадәт белән олылап, кодаларымыз дип дәшәләр. Зөһрә ханым, Сөембикәне биргән халык белән очрашуга мин гомерем буе ашкындым, диде кичәдә.

Җырчының Әстерхан төркиләрен, Сөембикә ханбикәнең тарихын шактый тирән белүе белән күңелләребездә соклану уятты. Зөһрә Сәхәбиева Әстерхан сәхнәсенә профессиональ артистлардан беренче буларак, Казан ханбикәсе-Йосыф морза кызы-Сөембикә ханбикэ образын күтәрде.

*Әстерханда Зөһрә Сәхәбиевадан «Җидегән чишмә» җыры калды.*

## Концерт в фонд поддержки мечети Сююмбике

С предложением об организации благотворительного концерта в фонд строящейся мечети Сююмбике, я вышла к Народной артистке республики Татарстана Зухре Сахабиевой-Бигичевой. У нее целый блок концертных номеров, посвященных Сююмбике, и Зухра ханум с удовольствием согласилась на благотворительный концерт. Зухра Сахабиева-Бигичева первая, кто из профессиональных артистов подняла образ Сююмбике на Астраханской сцене. Этот первый концерт, прежде всего, имел огромное духовное значение к возвращению Сююмбике к своему народу.

После концерта, в 2009 - 2010 годы, я продолжала собирать деньги для строительства мечети Сююмбике, в основном у себя на рабочем месте - в Областной клинической больнице №2 им. проф. И.Н. Аламдарова. Я вела список, деньги давали сотни людей: ногайцы, татары, казахи, туркмены и др. Пациенты, даже инвалиды, из сел передавали деньги, пусть небольшую сумму, через друг друга для мечети. Список будет официально оформлен и в дальнейшем передан для хранения вовновь созданном музее (в клубе) с. Растапуловка. По мере накопления обычно звонила имаму с. Растапуловка Зайнулле Айсаевичу Айналиеву (в прошлом врач). Акцентирую внимание своих читателей на имя Зайнулла эфенди, который возглавил, организовал строительства мечети Сююмбике от начало до конца. Альхамдуллахи, строительство завершено. Во время перерыва «Джанибевских чтений» в 2014 году, специально пошла в мечеть посмотреть все своими глазами. Мечеть красивая в нежно зеленом тоне. После обеденного намаза делала дуа (татары говорят дога) Зухре Сахабиевой и всем, кто внес пожертвования для строительства мечети. После чего еще посидела в мечети, энергетика хорошая, успакаивает. Поневоле перед глазами прошла трагическая судьба Казанской царицы-дочери ногайского хана на этом свете. Ханбикәбезнең рухы тыныч, шат булса иде. Амин!

***Наиля Потеева***

## Сөембикә-ханбикәнең соңгы эзләре - где твои следы Сююмбике?

Сөембикә көчле нугай нәселененең төрки доньясында, Рәсәйдә танылган сөекле баласы. Нугайлар үзара, бигрәк тә нәсел-ыруы, карендәшләр даими аралашып яшиләр, ташлашмыйлар. Бу хан заманнарыннан килгән, бүгенге көндә дә сакланган нугай тәртибе.Үзараларында танылган, башка халыклар алдында дан казанган шәхесләре белән алар чиксез горурланалар. Сөембикә Казаннан алып кителгәч, нугай ягы: баштан атасы-Йосыф морза, ул үтерелгәч, ир туганнары, аның турында кайгыртып яшиләр. Рус патшасына хат язып, кызларын оныклары белән кайтарып бирүләрен таләп итәләр. Рәсми рус елъязмаларында хәтта Исмәгыйль морзаның да Сөембикәне кайтаруын сорап язган хатлары теркәлгән. Сөембикәнең атасыннан соң да көчле, гайрәтле ир туганнары шактый була. Аның Касыймдагагы бәрелепсугылып, җәберләнеп яшәве доньяга таралып, Нугай иленә дә килеп ирешә. Иван Грозный, ничә тапкыр сорапта бирмәгәч, нәсел-ыру Сөембикәне сорамыйча да, орламыйча да алып кайтканнар дип саныйм. Кайту юллары: Касыйм - Хаҗитархан - Әстерхан ханлыгы, Исмәгыйль морза, нугай биләмәләре аша - Сарайчикка. Казан тарихчыларыннан, 1970 еллар тирәсендә Казан археологы - татар кешесе Әстерхан тирәсендәге бер татар-нугай авылы янында гайрәтләнеп Сөембикә кабере дип ышанып, бер каберне ачканын ишеткәнем бар.

Җаек-Урал елгасы буенда калкулыкта урнашкан Сарайчик (хәзер Казахстан җире) нугайларның гомерлек төп йорты. Сарайчиктагы мемориаль комплекс-некропольдә нугайның данлыклы морзалары, асыл затлары-ирләре күмелгән. Бүгенге көндә Йосыф, Исмәгыйль һ.б морзаларның кайда ятуы нугайның кирәк кешеләренә төгәл мәгълүм. Ханнар заманында, элек некрополь зур биләмәләр биләгән. Җаек-Урал елгасының биек яры даими рәвештә убырылып барганга, некропольнең күп өлеше инде җимерелеп төшеп, су астында калган. Бу процесс елдан-ел көчәя бара. Некрополь каршында, авыл башында, ялгыз, билгесез бер кабер бар. Ул «Кыз әүлия» кабере дип атала. Әүлия өстенә халык еракларданд килә. Кабер өстендә ак әләм җилферди, аны карап торалар. Кабер өстендә кызыл балчыктан эшләнгән таш кисәкләре чәчелеп ята. Без шундый таш кисәкләрен Алтын Урдага-Сарай әль Мәхрүсәгә баргач, җир өстендә күрәбез. Сөембикәнең мәңгелек урыны шул булырга мөмкин. Кабер XX гасыр башында тимер рәшәткә белән тотып алынган. Казахстанда казу эшләре алып баручы Әстерхан археологлары, тарихчылары аша кергән ул фотоны мин Казанда мәгълүм кешеләргә 3-4 ел элек биреп куйдым. Сарайчикта эшләүче археолог сүзеннән, Җаекның текә ярлары ныгытылмаса, киләчәктә некрополь тулысынча су астына китәчәк.

***Дин - исламга куәт бир!***

***«и ты увидишь, что люди толпами станут принимать веру Аллаха,...» (сура «Помощь» аят 2)***

## Известные люди принявшие ислам

Профессор Башкирского госуниверситета Нажип Валитов научно доказал существование всевидящего и всеслышащего Бога.

Строгим языком формул профессор Валитов доказал, что любые объекты во Вселенной взаимодействуют друг с другом мгновенно, независимо от расстояния между ними. Мысль материальна, уверен ученый, и ее можно мгновенно засечь из любой точки Вселенной.

**Газету подготовила со своими материалами и фотографиями Лауреат “Сююмбике беләзеге”, председатель Астраханского областного общественного объединения “Сююмбике” Потеева-Фатыйхова Наиля Шакирзяновна, E-mail:npoteeva@mail.ru**

Газета «Житель». Зарегистрировано Нижне-Волжским управлением Федеральной службы по надзору за соблюдением законодательства в сфере массовых коммуникаций и охране культурного наследия. Свидетельство о регистрации ПИ №ФС9-0753 от 31.05.2005г. Учредитель - Олег Васильевич Шеин:(8512) 51-12-87. E-mail: shein72@mail.ru. Адрес редакции: Россия, 414000, г.Астрахань, ул. Советская,8. Главный редактор Паршина Надежда Владимировна. E-mail: astsr-30@ mail.ru. Верстка выполнена на собственном оборудовании. Отпечатано: в Типографии «Триада» ИНН 3016041921. Адрес: 414056 Россия, г.Астрахань, ул.Савушкина, д.61-А Подписано в печать (по графику и фактически) 13.05.2014 г. Сдано в печать в 13.00. Тираж 2500 экз. Заказ № 182-Т.